**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**№ 2 КАРАР**

II чакырылышның чираттан тыш утырышы Урыссу ш.т.б. «27» февраль 2015 ел

Ютазы район Советының
"Ютазы муниципаль районы муниципаль
учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче
зат һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль
учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре,
мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре
турында белешмәләр бирү турында
Нигезләмәне раслау хакында"
13.04.2013 елның №14 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 22.12.2014 елның № 431-ФЗ санлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Президентының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 23.06.2014 елның № 460 санлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы район Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 13.04.2013 елның № 14 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Ютазы районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Ютазы районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасы;

Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керә торган затның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасы;

Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә

формасы;

Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасы;

2. Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен гамәлгә куючылар функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Ютазы муниципаль районы хакимиятенең башкарма органнарына әлеге карарны ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге карар «Ютазы таңы» район газетасында басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 01.01.2015 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы –<br>
Ютазы район Советы Рәисе Р.М. Нуриев

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының
«27» февраля 2015 ел № 2
карарына кушымта

Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре,чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы хакында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы, 22.12.2014 елгы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында»гы 431-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 23.06.2014 елның № 460 санлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.02.2013 елның «Татарстан Республикасы Дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы № 137 санлы карары нигезендә эшләнде, һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре, Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре (алга таба - муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре) вазыйфаларына керә торган затлар тарафыннан алынган керемнәре, чыгымнары, милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милек хокукындагы чыгымнары, мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибен билгели (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр).

2. Ютазы муниципаль районының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Ютазы муниципаль районының муниципаль учреждениеләрен гамәлгә куючылар функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма органына Россия Федерациясе Президентының 23.06.2014 елның «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы № 460 санлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла:

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларына керүче затлар тарафыннан – эшкә кергәндә;

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан – ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча.

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат эшкә кергәндә түбәндәге белешмәләр тапшыра:

а) муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) аларның милек хокукындагы чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр.

4. Муниципаль учреждение җитәкчесе ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына булган чыгымнар, милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына аларның милек хокукындагы чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр.

5. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылыш тапмавын яисә тулысынча чагылыш тапмавын, яисә хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән белешмәләрне хисап елыннан соң килүче елның 31 маеннан да соңга калмыйча тапшырырга хокуклы.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан әлеге пункт нигезендә тапшырылган төгәлләштерелгән белешмәләр срокны бозып тапшырылган дип саналмый.

6. Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керә торган зат тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Ютазы муниципаль районының муниципаль учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма органы карары белән гамәлгә ашырыла (алга таба – гамәлгә куючы), яисә мондый вәкаләтләрне гамәлгә куючы тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә бирелгән затлар.

7. Әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай

ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тапшырыла торган белешмәләр конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

8. Гамәлгә куючының үз вазыйфаи бурычларына керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр белән эшләү кергән, аларны таратуда яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда куллануда гаепле вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

9. Әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат муниципаль учреждение җитәкчесенең шәхси эшенә теркәп куела.

10.Әлеге Нигезләмә нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, күрсәтелгән белешмәләр аңа язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язма гариза булмаганда юкка чыгарылырга тиеш.

11.Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кергәндә затның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тапшырмавы яки тапшырмавы күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12.Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләрнең тапшырылмавы, эш бирүче тарафыннан аңа ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, үзе белән төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигез булып тора (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты).